**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 15.07.2020** **№ 547**

**Биектау муниипаль районы башкарма комитетының 2019 елның 30 апрелендәге 592 нче номерлы «Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турында кодексы, 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законы, 2020 елның 24 апрелендәге 17-ТРЗ номерлы «Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-2019) таралу нәтиҗәләрен булдырмауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Биектау муниципаль район башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2019 елның 30 апрелендәге 592 номерлы карары белән (23.09.2019 № 1617, 02.04.2020 № 339 карарлары редакциясендә) билгеләнгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә, түбәндәге эчтәлектәге 29 нчы пункт белән тулыландырып, үзгәрешләр кертергә:

| № | Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексы статьялары исемлеге (алга таба – ТР КоАП) | Вазыйфаи затлар исемлеге |
|---|---|---|
| 29 | ТР КоАП ның 2.17 статьясы «Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-2019) таралу нәтиҗәләрен булдырмауга һәм бетерүгә | - «Административ-техник инспекция» МКУ начальнигы<br>- «Административ-техник инспекция» МКУ баш белгече |

| | | |
|---|---|---|
| | юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү» | - «Административ-техник инспекция» МКУ әйдәп баручы белгече<br>- «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ җитәкчесе урынбасары (төзелеш, архитектура һәм ТКХ буенча)<br>- «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ җитәкчесе урынбасары (икътисад мәсьәләләре буенча)<br>- «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча)<br>- «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ җитәкчесе урынбасары - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МКУ начальнигы<br>- «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ эшләре белән идарә итүче<br>- «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ икътисад бүлеге баш белгече<br>- «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы<br>- «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ әйдәп баручы белгече (хәрәкәт иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлек юнәлеше буенча) |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат

порталындагы рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.П. Афанасьевка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин